84(2Рос=Тат)
М63



Лена Мингалиева

# Безнең гомер - бер мизгел

С наилучшими пожеланиями читателям центральной библиотеки от автора.

[signature]

Июн. 2013 г.

84(2Рос=Тат)
М61

Лена Мингалиева

# Безнең гомер-бер мизгел

Казан
2013

МБУ «Централизованная
библиотечная система»
Инв №76970/2(-)



# Кереш сүз.

Кеше күңелендәге тойгыларның агышын елга агышына охшатып була микән? Могаен, буладыр. Күңел агышының да ярсып шаулаган гайрәтле бусагалары, җәелеп аккан тугайлары, шомлы чоңгыллары һәм чит күзләргә күренмичә генә, сабыр һәм тын гына гомерлек уйга калган яр куеннары була.

Аларны газиз күк йөзе генә күрә һәм аңлый. Һәркемнең әлбиттә үз күге, үз күңел агышы...

Яңгыр җиле тәбигатьнең серле халәте. Кинәт искән җил кебек яисә көттереп килгән яңгыр кебек туа шигъри хис тә. Гомер сукмагында аллы-гөлле чәчәкләр генә балкып утырмый. Әлеге сукмакта кешене зур югалтулар, көенечләр сагалап тора. Ләкин, барыбер, яшәү-бәхет.

Күңелеңә доньяның яңгыр җиле кагылган икән, син гамьсез генә яши алмыйсың. Тормышыңның, яшәешеңнең һәр мизгеле сүзләргә күчә, шигырьгә әверелә...

***

Бер гомергә тиң түгелме,
Сызылып таң атулары?
Тирә-якны нурга күмеп,
Кояшның балкулары?
Җаннарыма дәва була,
Эчсәм чишмә суларын.
Хәтфә үләннәрдә аунап,
Тыңлыйм тургай моңнарын.
Һәрбер мизгел-бер гомер бит,
Аңлап кына әгәр яшәсәң.
Туган җирнең, сөйгән ярның
Кадерләрен әгәр белсәң.
Җилләр белән кире кайтмый,
Узган яшьлек еллары.
Онытылмаслык бер мизгел бит,
Безнең тормыш еллары.

***

Яшьлек үткән, картлык җиткән,
Күңел генә калган яшь килеш.
Яшьлегемне уйлап салып куям,
Хәтер сандыгыма шул килеш...

***

Мин яратам сине, тормыш!
Язың, көзең, җәең булганга,
Салкын кышта җылы тының белән
Җаннарыма сулыш өргәнгә.

***

Безнең күңел-бәллүр савыт кебек,
Ялгыш сүздән күңел кителә.
Әрнетмәгез җанны авыр сүзләр белән,
Болай да бит яшем түгелә...

***

Язмышлардан сабак алу,
Булса да безгәтаныш.
Тик нигә соң ялгышларны,
Үзгәртә алмый язмыш...

***

Күзләр житсә-моңсуланам,
Үтте диеп, тагын җәем...
Ник боегып торам әле,
Алда әле тормыш язым!

***

Тормыш-диңгез, кем ялгышмый?
Бу донья корабында.
Куркып калма, алга кара,
Бирешмә дулкыннарга!

***

Сагынуларым шундый көчле,
Түзә алмам инде төсле.
Ашкынамын синең янга-
Узып китеп искән җилне.

***

Яңгыр тамчылары тәрәз какты,
Җылы җилләр мине назлады.
Күтәреп лә килгән яңгыр төсле,
Сүнгән хисләр кабат яңарды.
Күңелемә керде яңгыр җиле,
Гүя яшьлек кайтты яңадан.
Җылы яңгыр бәхет алып килде,
Яшәү шатлыкларын кабаттан.
Яңгыр аша синең сынны күреп,
Кулым сузып сиңа йөгерәм!
Күк күкрәсә, югалырсың диеп,
Кочагыңа кереп сыенам.
Җәйге яңгыр, яу син, әйдә,
Килдең бит син җилләр белән.
Серле халәт-шундый рәхәт,
Аерыласы килми шул синнән.

***

Акыллы булалмадым,
Әйтелмәгән сүзләрем.
Мәгънәсезгә яшәмәдем,
Изге булды уйларым.
Гомер үтмәде лә әкияттәй,
Шатлыкны да бирде чамалап.
Югалтулар булды байтак кына,
Сыгылмаска булды бер сабак.

***

Яртı гомер артта калды,
Чәчләремә инде чал керде.
Күңел генә нигә гел сыкранды,
Кемне сагынып шулай яшәлде?
Дөньям тигез, бар да җитеш,
Нигә соң юк җанга тынгылык?
Сулар һавам чиста булсын диеп,
Ходайдан мин сорыйм тынычлык.

***

Дөнья мәшәкатен куып,
Вакыт үлчәүләрен оныттык.
Ялгыш басып шул үлчәүгә,
Язмыш ялгышларын үз иттек.
Уйланулар миңа тынгы бирми,
Кайда ялгыштым соң, аңламыйм?
Бу боталчык дөнья үзе серле,
Язмышымны барыбер каргамыйм.
Ялгышларым мине гелән,
Артка таба тарта сыман.
Тамыр җәйгән чүп үләндәй,
Үрмәкүчтәй сырып алган...

* * *

Үкенәсең, иртәрәк дип,
Килмәдем дип бу дөньяга,
Соң килсәң дә, әйтче миңа,
Нәрсә кылдың син файдага?
Син,дускаем, һич кайгырма,
Соңладым, дип, бу доньяда.
Кеше килә-китәр өчен,
Эз калдырып бу җиһанда.

* * *

И, бер аллам!
Мин бит синең бер фәкыйрең.
Бирче мина бер киңәшең,
Кайда синең бар кодрәтең?
Бәндәләрең бит онытты,
Изгелекнең җан рәхәтен.
Мәрхәмәтсез бозык җаннар
Күбәяләр бездән алда.
И, ходаем, бир син акыл,
Ялгышлардан үзең сакла.

* * *

Акыллылар белән исәрләр
Синең янда бик күп булыр,
Ялагайдан ерак йөрче —
Ышанычың белән уйнар.
Агу бирсә,әгәр аксакал,
Бер ни булмас,эчсәң дә син.
Икейөзле бал бирсә дә,
Сак була күр, читкә түк син.

***

Яшәү көчем артсын дисәң,
Мескен булма,булма ялагай.
Яшеннәрдәй яшьнәп яшә,
Булма алдатучан нажагай.
Юлдаш итеп сайла тугры дусны,
Мескенлекне гомер сөймә син.
Горур булсын башың, уең изге,
Кеше ялгышыннан көлмә син.
Егыласың икән, тор да,йөгер!
Ялгышларың артта калдырып.
Гарип күңел белән яшәү читен,
Яшә җирдә утлар яндырып.

***

Күңелдәге минем тойгыларым,
Елга агышына охшаган.
Җәелеп агып иркен тугайларга,
Куе урманнарга сыенган.
Шомгыл чоңгылларны урап узып,
Борылышта туктап калмаган.
Бәрелмичә каршы ярларына,
Сабырланып кына тик аккан.
Су агышын бары күреп тора,
Зәңгәр күктә йөзгән болытлар.
Яшьлек адымнарын саклап калган,
Елга буйларында сукмаклар.

* * *

Җырлама син мина шул җырынны,
Сүзләреннән ахры, исердем.
Хәйран калып синең моңнарына,
Кыяларга килеп бәрелдем.
Челпәрәмә килде хыялларым,
Бар максатым, яшәү рәвешем.
Йолдыз булып күккә атылдым да,
Очкын булып җиргә сибелдем.
Бәллүр савыт кебек ватылдылар
Күңелдәге кайнар хисләрем.
Җырладың да, китеп бардың,
Ишетмәдең йөрәк тибешен.

* * *

Язгы таңда тәрәзәмне ачам,
Кояш җырын ишетеп куанам.
Ай-кояшны, якты көнне күреп,
Шушы халәтемә шатланам.
Таң җиледәй күңелем җырлый,
Йокы керми күзгә бу таңда.
Йолдызлар да ничек җемелдәшеп,
Атылалар серле җиһанда.
Йолдызларга карап соклануым,
Килә минем бала-чагымнан.
Йолдызлардай балкып яшик, дисән,
Китмә, җаным, минем янымнан.

* * *

Туган ягым, сина кемнәр генә,
Җырламаган сагыну җырларын.
Сары конбагыштай сагышланып,
Йокысыз үткәрмәгән таңнарын.
Донья куып, мәшәкатьләр белән,
Көн артыннан көннәр үтсә дә.
Өзелә үзәк, сызлый күңел,
Туган яктан җилләр иссә дә.
Исләремдә һаман чишмәләрнең
Челтер-челтер аккан җырлары.
Бер кайгысыз чаклар синдә үткән,
Акбуз аттай бала чакларым.
Болыннарда алсу чәчәкләрнең
Хуш исләре нигә онытылмый?
Туган якларымның моңнары
Күнелемдә һаман, һич тынмый.
Яшел тугайларда айлы кичләр,
Бергә каршылаган алсу таңнар...
Хәтирәләр белән һаман яшим,
Онытылмый икән җан дуслар.
Чит җирләрдә яшим, күпне күрдем,
Бер ни җитми туган ягыма.
Болытларга ияреп, кошлар кебек,
Кайтсаң икән яшьлек язына...

Тормыш юлы-тузанлы юл.
Истә аның һәрбер сукмагы.
Акыл белән яшәлсә дә кебек,
Бирде тормыш авыр тукмагын.
Акыл һәм хис, ә йөрәгем кая?
Нигә бирми бирәр киңәшен?
Әллә булдым гел саңгырау,
Ишетмәдем йөрәк тибешен...
Гомер уза, диеп, кайгырмаем,
Узмады ул бушка, моң-зарда.
Якты көннәр, зур хыяллар,
Алсу таннар-барыр юлларда.
Язмышка мин үпкәләмим,
Һәркемнен бу җирдәүз юлы,
Бәхет дигән олы төшенчәне
Үзе таба, үзенә юлдашны.
Уфтанмаем, дуслар, алда-гомер,
Йөрәк тибә, димәк мин яшим.
Сандугачлар кебек язгы таңда,
Бергәләшеп яшик гөрләшеп.

* * *

Сагынуларым язгы ташкын кебек,
Күңелкәем һаман сагышта.
Язмыш йөртә безне чит җирләрдә,
Туган ягым калган еракта.
Вакытларга ияреп яшьлек узган,
Чит җирләрдә гомер итсәм дә,
Җилләр кебек үткән,әй,яшьлегем,
Онытылмый еллар үтсә дә...
Еллар уза бара, йөрәк туза,
Сагышлардан әллә сызылып.
Сагынамын гүзәл яшьлегемне
Чишмә жырларына кушылып.
Кайтып булса икән яшьлегемә,
Сандугачлы авыл кичenә.
Бәхет кошы кебек очып кына
Мәхәббәтем,яшьлек иленә.
Гомер буе сагынып яшәлсә дә,
Чит җирләрдә ятлар булды иш.
Көннәр үтә, тормыш дәвам итә-
Күнел генә һаман яшь килеш.

# Сагыш

Җан яртысым, кайда соң син?
Җырда гына калдың әллә син?
Кайтавазым кебек сине көттем,
Әллә инде булдың искән җил...
Чәчләремнән бары әнкәм кебек,
Назлы итеп җилләр сыйпады.
Ярты җаным гелән сыкранды шул,
Төшләрендә елап уянды...

## Әнкәй җыры

Сагышлардан күңелем әрнегәндә,
Искә төшә әнкәм җырлары,
Ул җырласа-кошлар тына иде,
Яңгыратып ялан буйларын.
Синнән күчте инәй, бары синнән,
Туган җиргә булган мәхәббәт,
Авыл көен җырлап эштән кайту,
Булган икән рәхәт һәм ләззәт.
Өйрәттең син:изгелекләр кылып,
Матур яшәгез дип, балалар.
Онытылып бара нәсихәтең,
Балаларын-донья куалар.
Төшләргә дә сирәк керәсең син,
Тынычмы соң яткан урының?
Үкенечләр белән яшәлсә дә,инәй,
Гомер үтә сине сагынып.
Мендәрләргә башым терәү белән,
Килеп басасың күк каршыма.
Йокла балам, диеп эндәшәсең,
Кайгы килмәсен дип, башына.
Эх, кайтарып булса икән,
Шул чакларны, синең моңнарны,
Ялгышулар булмас иде кебек,
Өзгәләмәс иде җаннарны...

***

Гомерләр уза икән,
Күлмәкләр туза икән.
Агым судай вакытларны
Туктатып булса икән.
Искән җилләр исә икән,
Яшәү яме нидә икән?
Биек тауга менгән чакта,
Янәшәмдә булсаң икән
Кыялар биек икән,
Түбәсе күккә җиткән.
Менер өчен үз кыяңа,
Баскычлар куйсаң икән.

***

Гомер ярым-татлы назым,
Назларыңа мин сусадым.
Кил син миңа колач җәеп,
Үтмәгән бит яшьлек җәем.
Яшьлегемдәй назлы чагым,
Бүләк итәм сөю назын.
Искә алыйк яшьлек таңын.
Сандугачлы күңел моңын.
Иңнәренә башым куям,
Күзләремдә шаян очкын.
Тойгыларым көчле җилдәй,
Йөрәкләрдә уйный дулкын.
Җаннарыма дәва булып,
Яшә тугры ярым булып.
Язгы җилдәй назлы булып,
Карт имәндәй терәк булып.

МБУ «Централизованная
библиотечная система»
Инв № 76970

## Кызыма

Менә син дә үсеп җиттең,
Тал чыбыктай нечкәбилең.
Акылыңа, буй-сыныңа,
Күзләреңә-күз тимәсен.
Әле булса күз алдымда
Тәпи атлап киткән чагың.
«Әни» дигән татлы сүзең,
Бик яратам, сине, кызым!
Бәхетле бул, кызым минем,
Юлларыңа гел ак җәймә!
Тормыш юлың шатлыклардан
Балкып торсын синең, әйдә!
Теләгем бер сиңа кызым:
Күнел сөйгәнеңне эзлә!
Эзләп тапсаң-һич югалтма,
Пар алмаңны үзең өз лә!

***

Язлардан сөю эзләдем.
Җылы җилдән, җәйге кичтән.
Сөю килер сыман иде,
Кабатланмас хисләр белән.
Бөтен доньям шатлык иде,
Мәхәббәтем шундый көчле,
Назларым да сиңа иде,
Таң нурыдай алсу төсле.
Язлар инде күптән үткән,
Салкын көз дә килеп җиткән.
Сары яфрактай өзелеп,
Мине сөю ташлап киткән...

***

Сандугачның үз моңы бар,
Үзенә тиң иш-яры бар.
Сиңа гына җырлый торган,
Минем матур җырларым бар.
Аккошлардай парлы булсын,
Икебезнең барыр юл.
Парлы булсын канатыбыз-
Яшәү яме шунда ул.

# Әнкәм рухы

Әнкәм сүзе йөрәгемдә,
Багырьләрдә-иң түрдә.
Еллар үтә, онытылмый,
Әнкәй сүзе-күңелдә.
Авыр чакта искә төшә,
Әнкәй сүзе-рухи азык:
«Ялгышларны кабатлама,
Акыл белән яшә, кызым!»
Әй, син, тормыш, ник катмарлы?
Елатасың, көлдерәсең,
Әнкәем дә юк янымда,
Бирер иде бер киңәшен.
Тормыш давыл дисәләр дә,
Салкын җилләр иссәләр дә,
Давылларга каршы торам,
Әнкәемнең рухы белән.

* * *

Син минем җанымның яртысы, дип,
Әйтер җанны мин дә эзләдем...
Эзләдем дә, ләкин табалмадым,
Бәгырьләрем теленеп еладым...
Агым сулар белән акты бугай,
Яшьлектәге минем теләкләр.
Өмет белән гелән яшәсәм дә,
Бергә типми безнен йөрәкләр.
Язлар җиткән саен минем күңел,
Нидер көтте, никтер ашкынды.
Тәрәзәмә бәргән яңгыр белән,
Сагышларым тагын юылды.
Язмышымны һавадагы
Айга тиңлим, белмим, нигәдер...
Ул да ялгыз, зөһрә йолдыз аны,
Таң атканда гына үбәдер...

И, вакытның агышлары,
Бу гомер барышлары.
Ярларына бәрә дулкын,
Онытып сагышларын.
Дулкыннарны кичү өчен,
Кирәк янда чын дуслар.
Дуслар булса-яшәү җинел,
Матур үтә гомерләр.
Авырлыклар килсә әгәр,
Кем суза ярдәм кулын?
Дуслар белән яшәү ямьле,
Кем белә анын тәмен?
Гомерләрнең кадерен белеп,
Яшик без дуслар белән.
Бер тугандай бергәләшеп,
Шатлыклар белән гелән.
Сез дусларым-ярты бәхет,
Авыр сакларда терәк.
Шуна күрә бер-беребезнең
Кадерен белергә кирәк.

Яшьлек үтә диеп, хафаланма,
Гомер бит ул аккан сукебек.
Тормыш-моңсу җырга ошаса да,
Дәртле җырлар белән без яшик.
Вакыт үткән саен, еллар белән,
Акыл керә, безне үзгәртә.
Яшьлек ялгышлары артта калды,
Тик нәрсәдер җаның әрнетә?..
Моңсуланма әле — гомеркәең,
Бушка үтмәгән бит, заяга.
Тормышыңа бүләк — балаларың,
Алар һәрчак синең яныңда.
Сыкранмыйча үтеп чыктың,
Сикәлтәле тормыш юлларын..
Яшәү яме белән сөенеч бирә,
Оныкларың — синең дәвамың.

* * *

Исеңдәме, җаным, безнең яшьлек,
Агыйделнең алсу таңнары?
Искә алып, мин дә сагышланам,
Хәтеремдә-яшьлек еллары...
Әрнемәче, йөрәк, үткәннәргә
Юллар инде күптән ябылган.
Тормыш диңгезләрен аерым кичтек,
Араларга киртә корылган.
Төшләремә кереп, уянамын,
Хәтеремдә һаман май кичем.
Шомырт чәчәкләрнең исе белән,
Җырлап үзган минем яшьлегем!

* * *

Очрашудан, хушлашудан,
Тора безнең яшәү яме.
Айрылышу авыр булса,
Очрашуы бигрәк күнелле.
Салкын чишмә суларыдай,
Мәңге аксын безнен гомер.
Гомерләр бит безгә бүләк,
Кадерләрен белү зарур.
Җылы кояш нурларыдай,
Якты булсын хыяллар,
Айрылмыйча җырлап яшик —
Янда булсын балалар.

***

Яшь чагында донья матур.
Кызлар — гүзәл, асыл — егетләр.
Без бирешкән вәгъдәләргә,
Баглыйбыз зур өметләр.
Тормыш дәвам итә, вакыт үтә,
Әллә кая очкан вәгъдәләр.
Тупасланган күңел, үпкәләшеп,
Мәгънәсезгә үткән күп көннәр.
Күңел гөлен сулытмачы, бәгырь,
Алсу идем мин дә яшьлектә...
Бүләк итеп биргән ак чәчәгең-
Авыр сүздән шулай тиз шиңә...
Күңелемдә һаман бушлык,
Гомер буе көттем синнән наз,
Җылы сүзең, күз карашың
Кичкән икән ахры, миннән ваз...
Өлешеңә төшкән көмешең дип,
Яшәү ахры, дөрес түгелдер.
Гомерләр бит берәү генә килә,
Матур яшәү безгә тиештер.
Әйтелмәгән сүзләр йөрәкләрдә,
Күңел генәһәрчак сагышлы.
Кайтыйк бергәләшеп яшьлеккә без,
Соң түгелдер-төзәтик ялгышны.

Яраттым шул үзеңне.
Елмаюлы йөзеңә.
Җаным-тәнем кабул итте.
«Сөям» дигән сүзеңә.
Мәхәббәтле сүзләр белән.
Арбаттың син күңелне.
Саф күңелем бары синдә,
Әсир иттең йөрәкне.
Ярым бул син,дидең,
Сүзләреңә ышандым.
Яратуым көчле иде,
Сиңа гына табындым.
Мәхәббәт бит-серле дөнья,
Була икән анда ялгышлар.
Яратусыз-дөнья гамьсез,
Булмасын тик сагышлар.

***

Һәрбер сары-алтын түгел,
Тормыш ул тоз ялата.
Асыл ташлар ялтырашып,
Гомер буе сине алдата.
Алдашулар, алданулар —
Тормышның бер мизгеле.
Салкын көздә тәрәзәңә
Усал җилләр каккан шикелле.
Кызганыч ки,бүдөньяда,
Алыш-биреш алга куелган
Кешеләргә булган олы хөрмәт,
Күңелләрдә ахры, җуелган...

# Онытма

Кайчак безнең күңелләрдә
Истәлекләр икән җуела.
Бик кыскара икән хәтер,
Биргән вәгъдәләрең онтыла.
Онытыла дуслар изгелеге,
Туганыңның йөрәк җылысы.
Эреләнеп, әллә кемнәр булып,
Яшибез лә икән ваемсыз.
Үткәнеңә син ишегең япма,
Барла :күпме хата-ялгышың?
Гамьсез булма, әйт җылы сүз,
Җылы сүз ул-җаннар азыгы...
Ялгыштым шул, кичер диеп,
Гафу сорау әллә авырмы?
Күңелләрдән юшкын китәр иде —
Бер елмаю әллә кыенмы?

* * *

Йөрәгеңдә миңа урын юк,
Онытмансың безнеңүткәнне...
Минем сүзне, минем йөзне,
Карашымны, минем сөюне...

***

Бу дөньяда яшәүләре җиңел,
Дусларыбыз янда булганга.
Ачу тотма тормышка син,
Көенечләр күбрәк булса да.
Син яшисең гел сокланып,
Тормышыңда алсу таңнарга,
Бу дөньяда әле моңнар яши,
Рәхмәтле бул нурлы җиһанга.
Ничек яшәсәң дә, кабул ит син,
Бу дөньяны шулай бар итеп.
Яшәү-бәхет, үзе шатлык икән,
Ходайдан син сора түземлек.
Кайгырма син, гомер уза диеп,
Безнең гомер әле узмаган.
Яшьлектәге ялкын учакларын —
Бездән башка кемнәр кабызган?

Ак кышларда ап-ак карлар,
Карашларым ак карларда.
Бар булмышым сезнең янда,
Торып калган бураннарда.
Энҗе кардай яңа җырым,
Каралмаган һич хисләрем.
Ак карлардай уйный-оча,
Күңелдәге ак теләгем.
Яшәүөчен өмет биреп,
Ява тагын ап-ак карлар.
Җан җылымны сезгә бирәм,
Алда әле ап-ак юллар.
Бурандагы ап-ак кардай,
Булсын тормыш юлларыбыз.
Каралмасын уйларыбыз,
Балкып торсын бар доньябыз.

***

Авылыма кайттым җәйге ялга.
Күреп килим диеп дусларны.
Туганнарның хәлен белеп,
Искә алып яшьлек елларын.
Су буенда таллар минем кебек,
Чишмәләргә иелеп су эчә.
Сагынуымны сөйлим талгын җилгә,
Керер диеп минем хәлемә.
Әллә мин үзгәргән, әллә авыл,
Тик сандугач моңы шул килеш.
Зифа каеннарым да картайган,
Күңел генә калган яшь килеш.
Су буенда, яшь чактагы кебек
Янгырамый гармун моңнары,
Бары тасмалардан, төнне ярып,
Ишетелә чит ил җырлары...

***

Туган көнең котлы булсын,
Барлык дөньяң нурлы булсын!
Кышның ап-ак карларыдай,
Җаның-тәнең чиста булсын!
Язгы кояш нурларыдай,
Якты булсын хыялларың.
Җан-дусларың янда булсын,
Шатлыгын күр балаларның.
Кайгы-хәсрәт урап узсын,
Сине тормыш юлларында,
Гомерләрең озын булсын,
Мәхәббәтле учагыңда!

# Елларым

Күпме еллар безнең үтелгән,
Сөенечләр булган бу җирдә.
Шаулап-гөрләп язлар килгән,
Бәхет килгән безгә җәйләрдә.

Сез елларым, ашыкмагыз,
Калдырмагыз безне үткәндә,
Ашыкмагыз шулай киләчәккә,
Сулыш алыйк туктап аз гына.

Бу доньянын матурлыгын,
Тагын бер кат татыйк әле,
Ашыкмагыз сез,елларым,
Кабат гашыйк булыйк әле.

Ашыкмагыз сез,елларым,
Безнең бәхет алда әле.
Канатларны талпындырып,
Очасылар бар бит әле.

* * *

Безнең гомер - тик бер мизгел,
Кадерләрен белеп без яшик.
Киләчәкне беркем белә алмый-
Яшик җирдә бәхет өләшеп.

* * *

Ник яшәдем икән кеше өчен?
Сөйләмәсен диеп, гәйбәт сүзен.
Дөреслекне нигә исбатладым?
Әллә инде булдым исәр үзем.

* * *

Кемгә яшәү җиңел бу доньяда?
Аксакалдан сора җавабын.
Әйтер сиңа ул акыллы сүзен,
Тик яшерер синнән күз карашын.

* * *

Елыйсыңмы, рәхәтләнеп ела!
Яшен үтәр, яңгыр туктар.
Энҗеләрдәй күз яшеңнең,
Мәгънәсен ул соңлап аңлар...

* * *

Иелгән башны кылыч кисми, диеп,
Гомер буе башкаемны идем...
Ышанычым мине акламады,
Кисте башны кылыч-юкка идем...

***

Уйламыйча кайчак алдын-артын,
Чыгарабыз бар нәрсәгә хөкем.
Кул куярга сиңа гәйбәт сузгә,
Бармы икән,синең хакың?

***

Әй, син, кеше,яшә акыл белән,
Уйларыңда булсын изге ният.
Начарлыкны тырыш онытырга,
Яхшы эшең булсын гел үрнәк!

***

Адымнарны кабат атлап була,
Үткәннәрне булмый кабатлап.
Бик бәхетле яшәр кебек идек,
Хыялларны булса кадаклап.
Хыял бит ул ал таң төсле,
Озак тормый зәңгәр киңлектә.
Һаваларда очкан кошлар кебек,
Буй җитмәслек бездән биектә.

***

Китек күңел белән яшәү кыен.
Ышанычлы ярым булмадың.
Усал җилләр мине еккан чакта,
Син кайларга китеп югалдың?
Мин үтенеп ярдәм сораганда,
Син ишетеп, юри ишетмәдең...
Бозлы күңеленә жылы өрдем,
Кайнар сулышымнан эремәдең...
Аңламадың минем күңел моңын,
Йөрәгең гел булды саңгырау.
Ялварсам да, ничек еласам да,
Ишетмәдем парлы яңгырау.
Ялгызларга яшәү җиңел түгел.
Һәркем аңлый алар язмышын.
Кемнәр күрә белә, кемнәр аңлый,
Парлы ялгызларның сагышын?

# Яшьлегем хисләре



Бу шигырь юллары 1980-82 елларда Уфа педагогия училищесында укыган вакытта туган. Бүгенге күз белән караганда фикерләремдә гадилек, беркатлы самимилык чагылып тора. Кайбер шигырьләрем бөтенләй чиле-пешле кебек. Шуна карамастан да-алар минем саф күнел тойгыларым, сөю сагышларым, шатлыкларым, көенечләрем һәм тормышка мәхәббәтем... 30 ел вакыт үтеп тә киткән шул... Саргаеп беткән шигырь дәфтәремне кулга алсам, яшьлектәге кичерешләрем янадан күнелемне биләп ала...

## Карлар ява

Җиргә ап-ак карлар ява...
Карлар белән сафлык ява.
Кемдер бәхетен таба,
Ә берәүләр кабат югалта.
Карлар ява...
Күнелләргә аклык сибеп,
Хыялыма канат куеп,
Җиргә тагын карлар ява,
Карлар ява...

* * *

Күзләремнең нурлары — син,
Күңелемнең язлары.
Син өметем, якты нурым,
Йөрәгемнең назлары.

* * *

Китканеңә күпме генә булды,
Миңа инде гүя ел кебек.
Синең янда мин бәхетле идем,
Ул көннәрем татлы төш кебек...

***

Бәхетлемен, бик тә бәхетлемен,
Син булганда минем янымда.
Сынау алган чакта язмыш җиле,
Калдырма син юллар чатында.
Син булганга минем таңнар якты,
Күзләремнән нурлар түгелә.
Шатлык белән тула һәрбер көнем,
Юлларыма гөлләр сибелә.

***

Авыр икән, ялгыз чакларыңда
Серең сөйләр кешең булмаса.
Һәрбер таңың һәм кичләрең,
Шатлык белән әгәр тулмаса.
Нишләргә соң, үткәннәргә
Үкенүдән файда юк диләр.
Диләр... Әмма яшь йөрәккә
Сагыш тулганлыгын белмиләр.
Һәрбер язның үз мизгеле була,
Язлар да бит охшаш түгелләр.
Язлар кебек кешеләр дә,
Барысы да төрле төрлеләр
Кеше гомере тора мизгелләрдән,
Күпме кеше янып яшәгән!
Үткәннәргә кайтып булмагандай,
Аерылып та булмый үткәннән.

***

Бик сагынам сине, авылым,
Яшәгәнгә синнән еракта.
Күрер өчен кайтам дусларымны,
Булса да тик бары азга гына.
Колачымны җәеп,сиңа кайтам,
Каршыла син мине, авылым!
Хәтфә тугайларым, күк урманым,
Сезне шундый өзелеп сагындым!
Синдә үтте матур бала чагым,
Синдә күрдем тормыш мәгънәсен.
Саф хисләрем синдә бөреләнде,
Синнән еллар аера күрмәсен.
Төшләремә керә уйнап йөргән,
Кар сулары аккан тауларым.
Кая барсам, кайда яшәсәм дә,
Оныта алмам, сине, авылым!

## Дустыма теләк

Күңелеңдә синең нинди уйлар,
Сагыш дарьясымы ,шатлыкмы?
Үткәннәрең ничек һәм бүгенгең,
Мәхәббәтеңә син тугрымы?
Дустым димен, якын итеп сине,
Беләсем килә синең үзеңне.
Киләчәгең синең якты булсын-
Искә алырсың бер үземне.
Уйчан гына миңа син карыйсың,
Тик күзләрең нидер сөйлиләр.
Иртәнге чык кебек саф мәхәббәт,
Телим сиңа бары шат көннәр.

***

Очрашулар, хушлашулар —
Бу тормышның тик бер мизгеле.
Тау белән тау очрашалмый,
Бу хакыйкәт безгә билгеле.
Араларда еллар ятсалар да,
Ә күңелләр безнең бергә бит.
Синдә икән — бар язмышым,
Бар бәхетем минем синдә бит.
Әллә син булганга һәрчак иртән,
Балкып ата минем таңнарым.
Кояш бата ерак офыкларда,
Синдә генә барлык уйларым.

# Хыял

Хыял җитез, хыял шундый көчле,
Күпләргә ул очар канат күя,
Болытлардан югарыда йөртә,
Алып китә әллә кайларга.
Зәңгәр күктән йолдыз чүпләтә ул,
Сөйгәненә ярсу егеттән.
Хыял белән кеше матурлана,
Курыкмый ул хәтта үлемнән.
Хыялы бар кеше озак яши,
Хыялы бар кеше бәхетле.
Без яшибез бары хыял белән,
Тормыш язым, димәк, ометле!

* * *

Юкка гына кайчак бу дөньяда
Никтер ялгышабыз, кая ашыгабыз?
Авыр сүзләр белән йөрәкләргә,
Күңел яраларын салабыз.
Һәр ялгышу тирән эз калдыра,
Еллар үтсә дә ул уңалмый.
Бәгырьләрне сызып искә төшә,
Вакыт узса да шул, онтылмый.
Ялгышлардан кеше сабак ала,
Башкачарак карый доньяга.
Ялгышулар белән ашыгулар,
Булмасыннар иде тормышта.

## Дустыма

Күпме көннәр синең белән үтте,
Бергә йөрдек бер үк юллардан.
Тик кайчакта бала-чага кебек,
Үпкәләшә идек юк-бардан.
Барлык уйлар безнең уртак,
Һәрбер нәрсә безгә яңалык.
Синең начар кәеф миңа күчә,
Мин елмайсам, сиңа да шатлык.
Еллар үтәр. Ә бер вакыт,
Ваклаганда гомер елларын.
Җылы хисләр белән искә төшәр,
Бергә үткән студент еллары.

***

«Кадерлем», дипэндәшәмен сина.
Гомерлеккә ярым булырсыңмы?
Тормыш юлын бергәүтсәк,
Таянычым була алырсыңмы?
Мин яраткан серле күзләр
Назлап-сөеп миңа карыйлар.
Күңелемә сагыш тулганлыгын,
Әллә инде алар аңлыйлар?
Аңласаң да, еракларга киттең,
Килә бары сәлам хатларың.
Серле карашыңдай юаталар,
«Көт,онытма», диган сүзләрең.

Язлар килә,
Җиргә тагын ямьле язлар килә.
Күңелләрне назлап язлар килә,
Яшь йөрәгем тагын ярсып тибә,
Аяз күктә язгы кояш көлә.
Күңелемә җылы хисләр тула,
Гел көләсем, шатланасым килә,
Бар галәмгә учлап-сибеп,
Кешеләргә бәхет өләшәсем килә.
Яз килгәнгә инде әллә,
Күзләремнән нурлар сибелә,
Язларымда син килгәнгә,
Йөрәгемнән җырлар түгелә.

## Яз нуры

Шаулап-гөрләп ямьле язлар килде,
Күкселләнде кышкы урманнар
Яз җылысы белән таралдылар,
Күңелдәге моңсу томаннар.
Күрче, кояш ничек нурын сибә,
Һәркөн иртән чыга яктырып.
Таң нурлары белән уяна ул,
Бар доньяны нурга балкытып.
Урамнардан, тау буеннан
Гөрләвекләр ага челтерәп.
Ишетелә кичен гармун моңы,
Күңел кылларына чирттереп.
Ә кызлар соң, түзеп торамыни,
Гармун моңы үзәк өзгәндә?
Дәртле җырлар язгы кичтә,
Яңгырап тора авыл өстендә.
Ничек йөрәк җилкенмәсен инде,
Язгы җылы җилләр искәндә?
Язгы бөреләрдәй тулыша ул,
Мәхәббәте ташып килгәндә.
Табигатнең гүзәл матурлыгы
Язын миңа бигрәк сизелә.
Яз җылысы белән бергә,
Бар доньяма нурлар өстәлә.

***

Әллә нигә якын иттем сине,
Ныклап белмәсәм дәүзеңне.
Моңлы җырың, шаян сүзең белән,
Әсир иттеңүзеңә син мине.
Әйтер сүзләремне мин онытам,
Төбәлгәндә синең күзләрең.
Әле булса ишетәм кебек,
«Һандугасым» дигән сүзләрең.
Язгы ташкын кебек килеп кердең,
Яшьлегемә минем, күңелгә.
Синең янда бик кыюсыз үзем,
Төбәлгәнмен бары күзеңә.
Күзләремне йомсам,күз алдымда,
Кар бәрешеп уйнап йөргәннәр.
Җитәкләшеп йөрдек бакчаларда,
Кабатланса иде ул көннәр.
«Анлыйсым ла килә сине» дисең,
Күзләремә генә кара син.
Ышанырсын яратуым көчен,
Бар нәрсәдән биек икәнен.

***

Күптән көтәм синең хатларыңны,
Язарсың бит иркәм, ышанам.
Көнне-төнгә ялгап,төнне-көнгә,
Хыялыма таба юл алам.
«Сагынам сине» диеп, хатлар яздың,
Ышандым мин бөтен йөрәктән.
Нәрсә булды сиңа, хәбәрең юк,
Оныттыңмы әллә кинәттән?
Җиргә тагын ямьле язым килде,
Ничәнче кат көтәм мин аны.
Мин язларда сине озатып калдым,
Сагынып көтәм шуңа һәр язны.
Яз җилләре белән син кайтырсың,
Күңелем сизә шулай буласын.
Саф йөрәгем белән каршыларм<br>ын,
Сагынуымны шунда аңларсың.
Сине көтеп чәчәк атты гөлем,
«Тизрәк үс!» дип, көндә су сибәм.
Язгы нурдай балкып кайтчы иркәм,
Көтәм сине, ишетәсеңме, көтәм!

***

Нәрсә булды икән миңа бүген,
Кулларыма бер эш алалмыйм.
Күңелемә килә авыр уйлар,
Рәсемеңнән күзем алалмыйм.
Сагышларым, тизрәк таралыгыз,
Саргайтмагыз минем дөньяны!
Мәхәббәтем, мәнге шиңмәс гөлем,
Йөгерәм сиңа, каршыла мине.
Ишетәсезме таулар, мин сагынам аны!
Ишетәсезме, сезгә эндәшәм?
Күрәсезме күзләремнең нурын,
Шул нурларны аңа мин сибәм.
Сагынамын, үлеп сагынамын,
Күрә алмаенча түзәалмам.
Бөдрә чәчен иркәләсә җилләр,
Шул җилләрдән инде көнләшәм.
Нинди ярсу-әллә мәхәббәтме?
Уйларга да үзем оялам.
Телгәләмә инде бәгыремне,
Йөрәгемдә минем ут яна.

***

Шатлыкларың белән кил син миңа,
Син бит минем ике канатым.
Бу дөньяны син булганга ахры,
Сине шулай өзелеп яраттым!
Җитез җилем, оч син тизрәк,
Бәхеткәем, хыялым янына!
Очып бар да, әйт син ана:
«Ул һәр көнне сине сагына»

***

Ничәнче кат көттем, син килмәдең.
Сизмәдеңме минем көткәнне?
Белмәдеңме, өзелеп сагынудан,
Йөрәккәем ярсып типкәнне?
Ничек барсың, шулайкабул итәм,
Тормыш биргән миңа җәзаны.
Мин күтәрмен сине гомер буе.
Өзгәләмә генә җанымны.

***

Күп тәүтмәс, яшәрер бар дөнья,
Ак каеннар яфрак ярырлар.
Таралыр бар җиргә яз сулышы,
Язны мактап җырлар бар кошлар.
Язгы бөреләрдәй күңел тула,
Назлар көтә йөрәк дигәнең
Язгы ташкыннардай уйнап дулый,
Сизә ул да язлар килгәнен.
Дөнья балкып торган мәлдә,
Яхшылыклар килә эшлисе.
Гомерләрең бүе үкенмәслек,
Матур итеп килә яшисе.
Янып-көеп, җырлап яшик әйдә,
Нинди гүзәл, матур бу тормыш!
Кешеләргә бәхет бүләк итик,
Үзебездән тора бит язмыш!

* * *

Табигатьнең сере гаҗәп инде:
Гүя безнең белән шаяра...
Кичә генә буран уйный иде,
Бүген җиргә ап-ак кар ява.
Ябалаклап мамык карлар ява,
Аклыгыннан күзләр чагыла!
Күңелемдә җылы хисләр туа,
Йөрәгемнән җырлар агыла.
Күбәләктәй очып карлар уйный,
Килеп куна минем иңемә.
Әйтә төсле: «әй, син, кеше,
Ак күңелле яшә гомергә!»
Кешеләрдә булсын иде шундый,
Ак карлардай илаһи сафлык!
Керсез булсын иде күңелләре,
Өләшсеннәр иде гел шатлык!
Әй, табигать, син могъҗиза!
Әдәм баласыннан көчлерәк!
Яшәү тамырларым бары синнән,
Өзелмәсен иде иртәрәк!

# Туган җирем гүзәллеген, сөйлим сезгә төсләр белән...





*Тени. холст, масло,* **2007**



*Зимний ручей, холст, масло*



*Родимые поля. Холст, масло*



*Ранний снег. бумага. соус*



*Летняя ночь, бумага, пастель*



*Маки. витраж, стекло*



*Южная композиция*



*Горная река, холст, масло - 2007*



*Северный пейзаж, холст, масло - 2007*



триптих Северное сияние, бумага, пастель - 2013 (1)



*триптих Северное сияние, бумага, пастель - 2013 (2)*



триптих Северное сияние, бумага, пастель · 2013 (3)



*Двое, бумага, пастель*



*Закат над морем, бумага, пастель - 2010*



*Зима, бумага, пастель - 2010*



*Голубая луна, бумага, пастель - 2012*



*Морской пейзаж, бумага, пастель - 2013*



*Новый день, бумага, пастель - 2013*



*Розовый день. бумага. пастель - 2012*



*Снег в сентябре, бумага, пастель - 2013*



*Туман над рекой, бумага, пастель - 2012*



*Август, холст, масло - 2009*



*Летнее утро. картон. масло - 2007*



*Март. картон, масло - 2005*



*Морозный день, холст, масло - 2010*



*Морской пейзаж. холст, масло - 2006*



*Осенний пейзаж, холст, масло - 2009*



*Пасмурный день, холст, масло - 2005*



*Последний снег, холст, масло - 2005*



*Родные просторы, холст, масло - 2006*



*Зима, бумага, пастель - 2010*



*Закат. тон.бумага, пастель, 2012*



*Зима, тон.бумага, пастель, 2011*



*Лесное озеро, холст, масло, 2008*



*Лунная ночь, тон. бумага, пастель. 2010*



*Поздняя осень, тон.бумага, пастель, 2009*



*Северная река. холст. масло. 2008*

Отпечатано в ООО «ШиП»
г. Казань, ул. Декабристов, 186.
тел.: (843) 555-11-11, www.5551111.ru

Фрок

